СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22.10.2020 Әгерҗе шәһәре № 2-2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясен төзү турында

Яңа чакырылыш Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының 2020 елның 22 сентябреннән 5 еллык срокка яңа Совет сайлану белән бәйле рәвештә, балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясен төзү һәм оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен үтәү максатларында, «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2013 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 143-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында үрнәк нигезләмәне раслау хакында» (10.02.2020 ред.) 2013 елның 06 ноябрендәге 995 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елның 22 сентябрендә яңа чакырылыш белән 5 еллык срокка сайланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы вәкаләтләрен үтәү срогына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе төзергә.
2. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль

районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең составын расларга.

3. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләренә үз эшчәнлекләрендә түбәндәгеләргә таянырга:

Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре һәм балалар хокукларын яклау өлкәсендә аның тарафыннан ратификацияләнгән халыкара килешүләре, федераль конституция законнары, федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте актлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында үрнәк нигезләмәне раслау хакында» (10.02.2020 ред.) 2013 елның 06 ноябрендәге 995 номерлы карары, Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм актлары, шулай ук «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 143-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.

4. Әлеге карарны «Татмедиа» ААҖ филиалының «Әгерҗе хәбәрләре» («Агрызские вести») газетасында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының законлылык, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе А.Р. Вәлиев

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы Советының
22.10 2020 ел. № 2-2
карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең составы**

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Гыйльметдинова<br>Римма Ринатовна | – Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, **комиссия рәисе** |
| 2. | Зарипова<br>Альмира Таһировна | – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Әгерҗе районындагы социаль яклау идарәсе башлыгы, **комиссия рәисе урынбасары** (килештерү буенча) |
| 3. | Хәкимова<br>Эльвира Рәисовна | – Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясе баш белгече, **комиссиянең җаваплы секретаре** |
| | **Комиссия әгъзалары:** | |
| 4. | Обухова<br>Ксения Александровна | – Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясе баш белгече |
| 5. | Сафиуллина<br>Вәсилә Гарафетдиновна | – Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы “Мәгариф идарәсе" МКУ башлыгы |
| 6. | Сергеева<br>Татьяна Сергеевна | – Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте бүлеге башлыгы |
| 7. | Әхмәтова<br>Айгөл Фәритовна | – Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторының әйдәп баручы белгече |
| 8. | Гатауллин<br>Марс Мөбәракович | – Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы |
| 9. | Хуҗахмәтов<br>Тимур Рәсимович | – Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының полиция башлыгы - бүлек начальнигы урынбасары (килештерү буенча) |

| | | |
|---|---|---|
| 10. | Петряева<br>Елена Анатольевна | – Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының ОДН өлкән инспекторы (килештерү буенча) |
| 11. | Шәйдуллин<br>Айрат Разакович | – Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгы Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш идарәсенең Әгерҗе муниципаль районы буенча бүлек башлыгы, эчке хезмәт подполковнигы (килештерү буенча) |
| 12. | Караяни<br>Виталий Дмитриевич | – «Әгерҗе үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең психиатр-наркологы (килештерү буенча) |
| 13. | Мифтахова<br>Ксения Сергеевна | – «Әгерҗе үзәк район хастаханәсе» ДАССУ район педиатры (килештерү буенча) |